**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 24** **2015 елның 15 июне**

**Түбән Кама шәһәренең җирдән**
**файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 нче декабрендәге 20 нче номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – «кагыйдәләр») түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрдән 13 нче статьяның 4 пунктын, 14, 15, 16, 18, 19, 20 статьяларны, 7 нче бүлекне төшереп калдырырга.

13 нче статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә билгеләргә: «5. Җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Башкарма комитетның норматив-хокукый акты белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Гәрәевка йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А. Р. Метшин